КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 31 гыйнвар г.Казань № 53

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәме күрсәтү өчен яшь гаиләләрне исәпкә алу тәртибен раслау турында» 2018 ел, 10 декабрь, 1097 нче карары белән расланган Торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәме күрсәтү өчен яшь гаиләләрне исәпкә алу тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәме күрсәтү өчен яшь гаиләләрне исәпкә алу тәртибен раслау турында» 2018 ел, 10 декабрь, 1097 нче карары белән расланган Торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәме күрсәтү өчен яшь гаиләләрне исәпкә алу тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 пунктның 11 һәм 12 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

11) оешма реквизитлары белән эш урынынннан белешмә, ул гражданның эш урыны, аның вазыйфасы, алиментлары, эш бирүчедән алынган заемнар турында, оешма җитәкчесе яисә аның урынбасары тарафыннан кәгазьдә имзаланган һәм оешманың мөһере белән таныкланган яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза (эш бирүчедә булганда) белән имзаланган электрон документ рәвешендә – яшь гаиләнең барлык әгъзаларына;

12) кәгазьле хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар (хезмәт кенәгәсенең күчермәсе-оешма җитәкчесе яки кадрлар бүлеге башлыгы имзасы белән расланган барлык битләр («хәзерге вакытта эшли» тамгасы белән) яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән (эш бирүчедә булганда) имзаланган электрон документ формасында – яшь гаиләнең барлык әгъзаларына;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин